-

СОВЕТ ШЕЛАНГОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ШИЛАНГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

31.10.2023 г. № 32-188

РЕШЕНИЕ КАРАР

с. Шеланга

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлегенең Шилангы торак пункты территориясенең бер өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге Уставы ст. нигезендә, Шеланга торак пунктының бер өлеше халкы төркеменең инициативасын карап чыгып

Югары Ослан муниципаль районы
Шеланга авыл җирлеге Советы
Карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлегенең Шилангы торак пункты территориясенең бер өлешендә гражданнар арасында 2023 елның 14 ноябренә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга: “Сез 2024 елда Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлегенең Шилангы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 460 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

- Шилангы авылы Яр буе урамында урам яктыртуны ремонтлау

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Шилангы авылы, Яр буе урамы адресы буенча 96 нчы йорт янында 17.00 сәгатьтә гражданнар җыенын үткәрергә.

4. Шилангы авыл җирлегенең Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Шилангы авыл җирлеге башлыгы В.В.Майоров